Тәрбияче Зарипова Алсу Р.

Бәйрәм иртәсе “Хуш сөекле бакчабыз!

”Зал бәйрәмчә бизәлгән, шарлар эленгән. Музыка астында балалар залга керәләр.

А.б. Уза гомер аккан сулар кебек.
Үсеп бара безнең балалар.
Бакчабызда үскән сабыйлар
Мәктәпләргә инде баралар.

Кадерле әти-әниләр, килгән кунаклар! Ел да була торган дулкынландыргыч бәйрәм көнебез килеп җитте. Бүген бакчабыздагы балаларыбызны мәктәпкә, белем алырга озатабыз.

Кадерле балалар! Менә мәктәп яшенә кадәр үсеп җиттегез. Бакчага килгән беренче көнегезне хәтерегезгә төшерегез әле. Сөйләшә дә белмәгән, әле яңа тәпи киткән балалар инде мәктәп яшенә җиткәннәр. Әлеге бакчада шатлыкларыбыз да, борчуларыбыз да уртак булды. Бергә көлдек, бергә уйнадык, шаярдык. Бүген безгә бик моңсу. Шуклыклары белән безне сагайткан, уңышлары, шат авазлары белән сөендергән нәни дусларыбыз бездән китә. Алар безгә күпме күңелле мизгелләр бүләк иттеләр, зур ярдәмчеләребез булдылар. Ләкин барыбер күңелебез сөенә. Карагыз, алар барысы да нинди матурлар, исән-саулар, эш дигәндә мин-мин, дип, ял иткәндә җырлыйм-биим дип торалар, күзләре кызыксынудан янып тора.

Әйдәгез сүзне балаларга бирик.

Айсылу:
Килеп җитте бакчам белән
Саубуллашыр көннәр дә
Озакламый барыбыз да
Без китәрбез мәктәпкә.
Бик моңсу булса да безгә
Боегырга ярамый!
Бүген бит бездә бәйрәм

Бернигә дә карамый!

Айнур:
Любим музыку и сказки,
Наши песенки и пляски
Любим игры в День рожденья
Любим праздник и веселье
Здесь дружили мы, играли
Буквы первые узнали
Незаметно подростали
И совсем большими стали.

А.б. Бакчада без иң зурлар,

Их, шатланып туймыйбыз.

Яраткан җырларыбызны,

Яңгыратып җырлыйбыз.

Җыр: “Өйрәтәләр бакчаларда”

Рияз:
Ничә көннәр, ничә айлар
Кышын да һәм җәен дә
Сагынып сиңа килә идек
Бакчабыз һәммәбез дә.
Туган йорттай син кадерле
Син якын күңелләргә
Ничек кенә хушлашасы
Китәсе килми бердә.

Зөбәржәт:
Балалар бакчасында без
Дуслар булып яшәдек
Бик күп нәрсәләрне белдек
Бик күп җырлар өйрәндек.
Инде менә үсеп җиттек
Сау бул бакчам диябез
Китап-дәфтәрләрне алып
Без мәктәпкә китәбез.

А.б. Бакчада сез өйрәндегез,

Бик күп төрле һөнәргә.

Матур рәсемнәр ясарга,

Җырларга һәм биергә.

“Су буенда” т.х.б. (Кәрим белән Зөбәржәт бии)

Назилә:
Рисовали мы, лепили
Из цветного пластилина
На экскурсии ходили,
И играли с Буратино,
Динислам:
А ещё играли в прятки,
И водили хоровод
Возле ёлки в Новый год!
Кәрим:
Без дә үсеп җиттек менә
Мәктәпләргә барабыз
Тик кызганыч тәрбияче
Апаларсыз калабыз.
Дустым белән бергәләшеп
Без мәктәпкә йөрербез

Бары бишле генә алып
Сезне сөендерербез.

Рифнур:
А у нас сегодня праздник,
Радостный, веселый,
До свиданья, детский сад,
Здравствуй, здравствуй школа
Чтоб росли мы смелыми,
Добрыми, умелыми,
Знаем, все вы нас любили.
И хорошему учили.

А.б. Җыр да җырлыйк әле , апаларны зурлап
Бу җыр булсын бездән истәлек.
Көе калсын йөрәкләргә үтеп,
Гомер буйларына җитәрлек.

Кызлар башкаруында җыр: “Хәерле көннәр”

А.б. Балалар, сез тиздән мәктәпкә китәчәксез, ә бакчада сезнең нәни энеләрегез, сеңелләрегез кала, әнә алар да сезне котларга китсеннәр әле.

(Кечкенәләр чыгыш ясый, кулларында кыңгыраулар.)

Назилә:
Бездән бүләк итеп сез
Бу бүләкне алыгыз
Һәркөн иртән соңламыйча
Сез мәктәпкә барыгыз.

Миндияр:
Бездән бәләкәй булгансыз
Сез бакчага килгәндә
Кара ничек зур үскәнсез
Китәр вакыт җиткәндә.

Динислам:
Мин мәктәпкә барыр идем
Бернигә дә карамый
Тәрбиясе апа әйтә
Хәзергә бит ярамый.

Г.Шамиль:
Чәчәкләр тотып кулга,

Чыгасыз олы юлга.
Ә без сезгә уңышлар,
Теләп калабыз дуслар.
Фидан:
Тапкыр балалар сез,
Күп нәрсәләрне белдегез.
Зирәк, матур уйлар белән,
Белем иленә керегез.

Инсаф:
Мәктәпкә баргач та, дуслар
Бик тырышып укыгыз.
Яңа дуслар табыгыз,
Яманнан сак булыгыз.

А.б. Рәхмәт сезгә нәни дуслар,
Һәр сүзегез ягымлы.
Без дә сезгә бүләк итик,
Шушы матур биюне.

Күмәк татар халык биюе.

(Залга көй астына Белмәмеш көчкә генә портфелен күтәреп керә)

А.Б. Балалар, карагыз әле, кем безгә керә? Бу бит Белмәмеш!!! Кулында сумкасы да бар!

БЕЛМӘМЕШ. Я – алла, менә килеп тә җиттем! Сумкамны кечкә дигәндәй күтәреп килдем! Исәнмесез балалар! (исәнмесез) Сез монда нәрсә җыелдыгыз - ә ?

А.б. Исәнме Белмәмеш! Бүген безнең балалар, бакчалары белән саубуллашырга җыелдылар. Алар мәктәпкә барырга әзерләнәләр!!!

БЕЛМӘМЕШ. (Ачу белән) Ничек дип сез миңа дәштегез? Нинди мин белмәмеш!? Мин бетенесен дә беләм. Күрәсезме, минем нинди сумкам бар, һәтта аның билгеләре дә бар (сумкасын күтәреп шалтыратып карый).

А.б.. Димәк син дә безенең балаларрыбыз чикелле мәктәпкә җыендын!? Әфәрин! Ә нәрсә бар синең сумканда?

БЕЛМӘМЕШ. Укуда гел кирәк булган әйберләр.

Сумкасын ачып берәм-берәм әйберләр ала башлый.

_ Бу минем уенчыгым, дәрестә күңелселәнеп утырмас өчен! (погремушка)

_ Ә монда мин су салам, һәм барысынада сиптертәм! (сикалка)

_ монысы матурлык өчен. (Бусы)

_ Ә менә монсы, үземне яклар өчен! (рогатка)

_ Бу минем билгеләрем (цифра один и два)

Ин якын дусларым!!!

А.б.Алай икән, Белмәмеш, белмисен син нәрсә сумкага салырга кирәклеген _ әйбәт итеп укыр өчен. Менә хәзер сиңа безнең балаларыбыз күрсәтерләр.

Уен «КЕМ ДӨРЕС ИТЕП СУМКАСЫН ҖЫЯ»

БЕЛМӘМЕШ. Рәхмәт балалар . Хәзер инде беләм, ничек дерес итеп сумканы җыярга кирәк. (Җыелган Бер сумканы кулына тотып).

(Балалар җыелган сумканы Белмәмешкә бүләк итәләр).

А.б. Бик күңелле бакчабыз,
Тик сез генә китәсез..
Үзегезнең күчтәнәчне ,
Җырлап бүләк итәсез.

“Без инде хәзер зурлар”җыры.

А.б. Менә, балалар, бәйрәмебезнең ахыргы өлешенә җитәбез. Сезне 6 ел буена куеннарына сыендырган, тәрбияләгән, кайгырткан, сезнең өчен борчылган апаларга теләкләрегез дә бардыр.

Хәерле юл телиләр тәрбияче апалар,
Олы юлга озаталар, уңыш теләп калалар.

Кәрим:
Безнең яраткан бакчабыз
Гел матур булсын диеп
Безнең икенче өебез
Гел якты булсын диеп
Безгә һәрчак рәхәт, җылы
Күңелле булсын өчен
Безнең барыбыз т-да
Әнә шулай кайгырткан
Ул бит **Чулпан** апабыз
Аңа рәхмәт әйтәбез.

Айсылу:
Рәхмәт сезгә, бик зур рәхмәт,
Тәрбияче апалар.
Бездән соң да гөрләп торсын,
Шаулап торсын бакчалар.
Көйсезләнеп, еласак та,
Сез гел сабыр булдыгыз.
Безнең баштан сыйпап торды,
Сезнең йомшак кулыгыз.

Рияз:
Безнең Нафига апабыз
Һәрчак шат күңелле

Ярата ул чисталыкны
Тәртипне, матурлыкны
Һәрчак якты чиста булды
Матур булды бүлмәбез
Әнисә, Гәүһәрия, Нафига апага
Зур рәхмәт!

Рифнур:
Һәркөн иртән **Халисә** апа
Кереп хәлләрне белә
Витаминнар өләшеп
Авыртмагыз дия.

Айнур:
Өстәлләребездә һәрчак
Җылы аш булып торды.
Рәхмәт пешекче апаларга
Сызлаусыз булсын куллары.
Яткан урыныбыз чиста
Мендәребез йомшак
Фәрида апалар сезгә да
Рәхмәтле без һәрчак.

Зөбәржәт:
Безнең **завхоз** апабыз.
Бар эшкә дә җитешә.
Тәмле әйберләр ташый.
Бүлмәбез дә тәртиптә.

А.б. Алыгыз сез бүләк итеп,
Бүләкләрнең шушы матурын.
Каршылагыз тагын бик күп еллар,
Бүгенгедәй шатлык бәйрәмен.
(Балалар апаларга бүләкләр тапшыралар)

А.б. Хуш сөекле бакчабыз
Сау булыгыз апалар
Сезгә барысы өчен дә
Рәхмәт әйтә балалар.

Парлашып бер басыйк әле,
Һәр түгәрәккә чыгыйк.
Якты бакча залларында.
Туйганчы биеп калыйк.

“Прощальный вальс”(танец детей подг.группы)

Кадерле балалар! Сезне без дә барлык апалар исеменнән бәйрәмегез белән котлыйбыз. Сезгә киң һәм якты юллар, аяз күк йөзе, бәхетле мәктәп еллары, тел ачкычлары телибез.

А.б.: Аера белегез ак-караны
Начар юлдан йөрмәгез
Яхшы белән явызны сез
Берүк бутый күрмәгез
Шатландырыгыз ярдәм итеп
Ялгыз бер әбине
Үскәнем син матур диеп
Юатыгыз бер нәнине
Кеше булып яшик дисәгез
Булыгыз кешелекле
Бәхетле көн күрик дисәгез
Булыгыз игелекле.